РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Карамалинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 22, Азнакаевский район,
с.Карамалы, 423301,
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге
башкарма комитеты

Үзәк ур., 8нче йорт, Азнакай районы,
Карамалы авылы, 423301
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«02»июль 2025 ел.** **№ 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа турында» 21.12.2022 №43 карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитетына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешүне вакытыннан алда өзү турында 2025 елның 10 гыйнварындагы килешүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча муниципаль программа турында»21.12.2022 №43карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет «мәгълүмат-коммуникацион челтәре»ндә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А.Р.Ногманов